ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 3 » сентябрь 2018 ел № 147

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү хакында нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 5 мартындагы 52 номерлы Балтач муниципаль районы башлыгы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 2.1 статьясы нигезендә, Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү хакында нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 5 мартындагы 52 номерлы Балтач муниципаль районы башлыгы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү хакында нигезләмәнең 17 пунктында «Балтач район Советы аппараты җитәкчесе» дигән сүзтезмәне «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе» дигән сүзтезмә белән алмаштырырга.

1.2. Бәяләү комиссиясе составыннан түбәндәгеләрне чыгарырга:

Зарипова З.Р., Хакимова Р.Р.

1.3. Бәяләү комиссиясе составына түбәндәгеләрне кертергә:

Фәтхетдинов И. М. – Балтач муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, комиссия рәисе урынбасары;

Әшрәфҗанова З.А. – Балтач район башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге җитәкчесе.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы Р.Р. Нотфуллин